Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Гайтән авылы торак пункты
гражданнар җыены КАРАРЫ

«10» ноябрь 2022 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Гайтән торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Гайтән авыл территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1700 сум күләмендә акча кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм төзелеш контроле өчен түләү белән грунт катыш җәю.

2) Гәйтән авылында күперне ремонтлау.

3) Гәйтән авылында урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

4) Гәйтән авылында су белән тәэмин итү чыганагына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү.

5) Гәйтән авылында паркны төзекләндерү (эскәмияләр сатып алу һәм урнаштыру, үсентеләр алу).

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева

Гайтән авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Авдеева